РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ
БУИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БУА
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ

КАРАР

9 апрель 2026 ел

Буа шәһәре

№ 8-10

Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы
муниципаль берәмлеген БРИКС+ илләре шәһәрләре
һәм муниципалитетлары ассоциациясендә тәкъдим итү
турында

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә халыкара һәм тышкы икътисадый элемтәләрне гамәлгә ашыру максатларында Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Советы карар чыгарды:

1. Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Башлыгы Р. Р. Камартдиновка БРИКС+ илләре шәһәрләре һәм муниципалитетлары ассоциациясендә Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы муниципаль берәмлеген тәкъдим итү вәкаләтен бирергә.

2. Әлеге карарны Буа муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru. бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар имзаланган көннән үз көченә керә дип билгеләргә.

Буа муниципаль районы башлыгы
вазифасын башкаручы

И.Ф.Еремеев